## Туган телем – татар теле

# Туган илемне яратам

(5 нче дәрес)

# Туган ягы кирәк кешегә

Яшәр өчен бетмәс көч алырга

Олысына һәм дә кечегә, -

Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле

Туган ягы кирәк кешегә.

*(Фәнис Яруллин)*



# Өч матур сүз

\- Әйт син миңа өч матур сүз,
Уйлап әйт син, бәбкәем!
\- Мин яраткан иң матур сүз,
Иң матур сүз:
\- **Әнкәем!**
Калмый аннан бер матур сүз,
Һәрвакыт син әйткәнең.
\- Бергә әйткән ул матур сүз:
\- **Әткәем дә әнкәем!**
\- Бар өченче бер матур сүз...
\- Ул матур сүз:
\- **Илкәем!**
Анда бу йорт, төп бабамнар,
Илкәем – үз җиркәем!

*(Нәкый Исәнбәт)*

# Солдатлар



Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган.
Зур абый да солдат булып,
Ил чикләрендә торган...

Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына,
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим әле аз гына.

*(Клара Булатова)*

# Җирдә миңа ни кирәк?

Җирдә миңа ни кирәк?
Әти дә әни кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Без яшәгән өй кирәк!
Әти дә әни кирәк!
Без яшәгән өй кирәк!

Җирдә миңа ни кирәк?
Әллүкиле көй кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Тукай туган тел кирәк!
Әллүкиле көй кирәк!
Тукай туган тел кирәк!

Җирдә миңа ни кирәк?
Туган-үскән ил кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Мәңге имин Җир кирәк!
Туган-үскән ил кирәк!
Мәңге имин Җир кирәк!

*(Шәүкәт Галиев)*

# Мәкальләр

- Туган илең – туган анаң.
- Туган илем – туган өем.
- Үз илем – алтын бишек.
- Илдә яшисең икән – илеңә хезмәт ит.
- Балыкка – су, кояшка – һава, кешегә туган ил кирәк.





**Дәрес тәмам, дуслар!**

**Сау булыгыз!**